СОВЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

12.09.2024 Баулы шәһәре № 269

Баулы муниципаль район Советының 2020 елның 29 маендагы 265 номерлы «Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль милкендәге муниципаль мөлкәттән һәм җир кишәрлекләреннән һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен аренда түләве һәм пеня буенча бурычны түләтүгә һәм исәптән чыгаруга өметсез дип тану тәртибен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Баулы муниципаль район Советы **КАРАР ИТТЕ**:

1. Баулы муниципаль район Советының 2020 елның 29 маендагы 265 номерлы «Татарстан Республикасы «Баулы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль милкендәге муниципаль мөлкәттән һәм җир кишәрлекләреннән һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы территориясендә дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләреннән файдаланган өчен аренда түләве һәм пеня буенча бурычны түләтүгә һәм исәптән чыгаруга өметсез дип тану тәртибен раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга кушымтада:

2 пунктта:

2) пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. гражданинның, шәхси эшмәкәрнең банкротлык процедураларын, 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы «Бөлгенлеккә (банкротлыкка) төшү турында» Федераль законына ярашлы тәмамлау — күрсәтелгән Федераль закон нигезендә бюджетка түләүләр буенча ул түләү бурычын үтәүдән азат ителгән бурыч өлешендә;»;

2.1.) пунктчаны үз көчен югалткан дип танырга;

4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) җәзага хөкем ителгәннәргә карата штраф яисә суд тарафыннан карар кабул итү рәвешендә амнистия яисә ярлыкау турындагы актлар куллану, шуның нигезендә бюджет керемнәре администраторы бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтү мөмкинлеген югалта, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы тәмамлануга бәйле рәвештә;»;

5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) «Башкару эше турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 2 яисә 4 пунктында каралган нигез буенча башкарма документны түләтүчегә кире кайтарганда, әгәр бурыч барлыкка килгән көннән бурычлыга карата бөлгенлек (банкротлык) турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләр күләменнән артмаса, башкаручы суд приставы тарафыннан башкару эшен тәмамлау турында карар чыгарылганда банкротлык турындагы эш буенча производство ачу өчен биш елдан артык вакыт узган булса;»;

5.1.) пунктча белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

«5.1.) банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акчалар булмау сәбәпле, бурычлыны банкрот дип тану яки банкротлык турындагы эш буенча эшне туктату турында гаризаны суд тарафыннан кире кайтару турында акт кабул ителү;»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) адресы буенча һәм Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль район Советының икътисади үсеш, эшмәкәрлек, кече бизнес һәм коммуналь хуҗалык сораулары буенча даими комиссиясенә йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы Рәисе И.И. Гозәеров